**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 28 март № 196

г. Казань

Казан шәһәре чикләрендә Казансу елгасы акваториясендә 2017 елгы FIFA Конфедерацияләр кубогын һәм Red Bull Air Race World Series үткәргәндә су объектларыннан файдалану турында

Россия Федерациясе Су кодексының 6 һәм 25 статьялары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 23 апрель, 256 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләренең 1.3 нче пункты нигезендә, Казан шәһәре чикләрендә Казансу елгасы акваториясендә 2017 елгы FIFA Конфедерацияләр кубогын һәм Red Bull Air Race World Series үткәргәндә кешеләр гомере иминлеген тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Казансу елгасы участогында Ленин дамбасыннан алып Чуйков-Гаврилов урамнары чатына кадәр кечкенә суднолар, шулай ук җилкәнле, йөреп кайту, спорт өчен каралган суднолар, шул исәптән гидроцикллар, байдаркалар, ишкәкле көймәләр куллануны түбәндәге вакытларда тыярга:

2017 елның 18 июнендә 13.00 сәгатьтән 23.00 сәгатькә кадәр;

2017 елның 22 июнендә 16.00 сәгатьтән 2017 елның 23 июнендә 02.00 сәгатькә кадәр;

2017 елның 24 июнендә 13.00 сәгатьтән 23.00 сәгатькә кадәр;

2017 елның 28 июнендә 16.00 сәгатьтән 2017 елның 29 июненнән 02.00 сәгатькә кадәр;

2017 елның 20 июлендә 08.00 сәгатьтән 2017 елның 24 июлендә 14.00 сәгатькә кадәр.

2. Әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән судноларны куллануны тыю Казан шәһәре чикләрендә Казансу елгасы акваториясендә 2017 елгы FIFA

Конфедерацияләр кубогын һәм Red Bull Air Race World Series әзерләү һәм үткәрү өчен җәлеп ителгән судноларга кагылмый дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына:

әлеге карарның 1 нче пунктында кертелгән тыюны саклау максатларында, Казансу елгасы участогында Ленин дамбасыннан алып Чуйков – Гаврилов урамнары чатына кадәр кизү торуны тәэмин итәргә.

кертелә торган тыю турында халыкка мәгълүмат җиткерү эшен оештырырга, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша.

4. Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән берлектә, әлеге карарның 1 нче пунктында кертелгән тыюны саклау максатларында, Казансу елгасы участогында Ленин дамбасыннан алып Чуйков – Гаврилов урамнары чатына кадәр кизү торуны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\196.doc